**Татарстан Республикасы  Азнакай муниципаль районы**
**Вахитов  авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

Җиңү бистәсе № 99 2023 елның  "23" мае

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының  03.03.2011 елның №14 «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр” турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14.1 статьясы нигезендә Вахитов авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының  03.03.2011 елның  №14  «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр” турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның преамбуласында “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы” 2008 елның 17 гыйнварындагы №5-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 11.1 статьясы” сүзләрен “Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турындагы 2013 елның 25 июньдәге №50-ЗРТ Татарстан Республикасы кодексының 17 статьясы” сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турындагы нигезләмәдә:

а) 1 пунктта Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы” 2008 елның 17 гыйнварындагы №5-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 11.1 статьясы” сүзләрен “Татарстан Республикасы Муниципаль

хезмәт турындагы 2013 елның 25 июньдәге №50-ЗРТ Татарстан Республикасы кодексының 17 статьясы”  сүзләренә алмаштырырга.

б) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) актлары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге №103-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге №24-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм жирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Г.И. Аскарова